# КАРАР

**“16” ноябрь 2019 ел** **№2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау, Шушмабаш авылы, Сәгъдуллин урамында 281 м, Тукай урамында-321 м, Төнъяк урамында-281м;
- Шушмабаш авылында рөхсәтсез чүплекне каплау һәм бетерү;
- Шушмабаш авылында һәйкәлне ремонтлау?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 716 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 385 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 385 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында халык җыенын булып узган дип танырга,

халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:
- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау, Шушмабаш авылы, Сәгъдуллин урамында 281 м, Тукай урамында-321 м, Төньяк урамында-281м;
- Шушмабаш авылында рөхсәтсез чүплекне каплау һәм бетерү;
- Шушмабаш авылында һәйкәлне ремонтлау?
Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б йорт, Мәктәп урамы, 8 йорт, Мәктәп урамы, 5 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов